Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Березняк авыл җирлеге Советы

КАРАР

14 март, 2025 ел №4

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Березняк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Березняк авыл җирлеге Советы карары проектын хупларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы Кукмара шәһәре Советы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Березняк авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

3. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында» Березняк авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Шәрипов Рөстәм Фирдаил улы –комиссия рәисе;
Фәхретдинов Алҗберт Минһаҗ улы – комиссия әгъзасы;
Фатыхов Ренат Халит улы –комиссия әгъзасы.

5. Билгеләргә:

5.1. Гавами тыңлаулар үткәрү вакыты – 07.04.2025.

5.2. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты – 16.00 сәгать.

5.3. Үткәрү урыны – Березняк авыл мәдәният йорты бинасы, адресы: ТР, Кукмара районы, Березняк авылы, Ленин ур., 17.

6. Эшче төркемгә, ачык тыңлауларда кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Советы утырышында каракрга кертергә.

**7.** Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatar.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Березняк авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф.Шәрипов

Березняк авыл җирлеге Советының 2025 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарына 1 нче кушымта

Березняк авыл җирлеге Советы

КАРАР

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Березняк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге, кыскартылган атамасы – Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге (текстта алга таба – җирлек).».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авылы территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы: Р.Ф.Шәрипов

Березняк авыл җирлеге Советының 2025 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Березняк авыл җирлеге Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Березняк авыл җирлеге Советына кертелә адресы: ТР, Кукмара районы, Березняк авылы, Ленин ур., 17, яисә факс белән (84364) 35-2-02 кушымта итеп бирелгән үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма формада:

| т/б № | Статья, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А, адресы, телефоны, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр карар игълан ителгән көннән бер ай эчендә кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша: ТР, Кукмара районы, Березняк ав., Ленин ур., 17 йорт (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «гавами тыңлаулар» дигән тамга белән), шулай ук факс буенча (84364) 35-2-02 тапшырыла.

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Березняк авыл башкарма комитеты Секретаре тарафыннан теркәлә һәм, карау өчен, Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге башлыгына тапшырыла.

Җирлек башлыгы: Р.Ф.Шәрипов